**РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**ЧУАШ БОРНАЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**ДЕПУТАТЛАР СОВЕТЫ**

**КАРАРЫ**

**2014 елның 18 апреле 8№**

**Чуаш Борнае авыл җирлеге**
**җирләренән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен**
**раслау турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 32 статьясы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, муниципаль берәмлекнең тотрыклы үсеше, әйләнә-тирә мохитне һәм мәдәни мирас объектларын саклап калу өчен шартлар тудыру, муниципаль берәмлек территориясен планлаштыру өчен шартлар тудыру, физик һәм юридик затларның, шул исәптән җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектларының хокук ияләренең, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатларында, шул исәптән җир кишәрлекләреннән, капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән төрләрен һәм объектларын сайлау мөмкинлеге бирү юлы белән, шулай ук гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Чуаш Борнае авыл җирлеге депутатлары советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Чуаш Борнае авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләренең тәкъдим ителгән проектын үзгәрешсез һәм өстәмәләрсез расларга.

2. Әлеге карар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Әлки муниципаль районының
Чуаш Борнае авыл җирлеге башлыгы: И.Г.Зарипов